| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» октябрь, 2021 ел ОлыКайбыч ав. № 28

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 октябрендәге 22 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авылҗирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 октябрендәге 22 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (тәкъдим ителгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган 0,3 %, шулай ук «Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек хуҗалыкларын үз ихтыяҗлары өчен алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралгангомуми билгеләнештәге җир участоклары».»;

1.2. 1.2. 4статьянытүбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. Салым ташламалары.

Җир салымын түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

- гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле оешмалар (урманнар, урман парклары, парклар, скверлар, шосселар, проспектлар, урамнар, тыкрыклар, мәйданчыклар, тукталышлар, һәйкәлләр, яр буе, колонкалар, су объектлары, су башнялары, чишмәләр, коелар, артезиан скважиналары астында);

- зиратлар, үләт базлары һәм гражданнар зиратлары урнашкан җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле оешмалар һәм учреждениеләр;

- Татарстан Республикасы икътисад Министрлыгында аккредитация узган муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыклары администрацияләре;

- физик затлар – янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләре һәм әлеге статусны раслый торган документы булган ирекле янгын сүндерүчеләр.».

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/bkaybic-kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе А.И.Рәхмәтуллин